ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.10.2025 г. Заинск № 491

**Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 25 мартындагы 126 номерлы карары белән расланган инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча Муниципаль комиссиянең эш тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

РФ Хөкүмәтенең «Инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып күпфатирлы йортта торак урыннарны һәм гомуми мөлкәтне җайлаштыру чаралары турында» 2016 елның 9 июлендәге 649 номерлы карары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, инвалидның торак урынын җайлаштыруны һәм инвалид яши торган күпфатирлы йорттагы гомуми мөлкәтне инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып һәм инвалид өчен алардан файдалану шартларын тәэмин итеп, шулай ук, шундый бинада яшәүче затның инвалидлыгы белән бәйле рәвештә тормыш эшчәнлеген чикләү үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, инвалид ихтыяҗларын исәпкә алып, аларны җайлаштыру мөмкинлекләрен бәяләүне, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә, Зәй муниципаль районы Уставының 45 маддәсенә таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 25 мартындагы 126 номерлы «Инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда

инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча Муниципаль комиссиянең эш тәртибе турындагы Нигезләмәне һәм чаралар планын раслау хакында» карары белән расланган «һәм башка документлар» сүзләрен төшереп калдырып, инвалидлар яши торган күпфатирлы йортларда инвалидларның торак урыннарын һәм гомуми мөлкәтне тикшерү буенча Муниципаль комиссиянең эш тәртибе турындагы Нигезләмәнең 1 нче кушымтасындагы 4.8 пунктының 3 абзацына үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан мизгелдән законлы көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

Юрист
С.А.Филюшина
99050